Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Советы КАРАРЫ

2020 елның 28 августы 320№

Әлки муниципаль районы Советының
2016 елның 19 апрелендәге «Аерым
категория затларына чит ил банкларында
счетлар (кертемнәр) ачу һәм ия булуны,
акча һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны
тыю хакындагы Нигезләмәне раслау турында»
33 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2013 елның 7 маендагы «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм ия булуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) аннан файдалануны тыю хакындагы Нигезләмәне раслау турында»гы 79-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Советының 2016 елның 19 апрелендәге «Аерым категория затларына чит ил банкларында счетлар(кертемнәр) ачу һәм ия булуны, акча һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны тыю хакындагы Нигезләмәне раслау турында»гы 33 номерлы Карарга (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 1.8 пунктына «,шулай ук күрсәтелгән затлар куллана торган чит ил финанс инструментларына һәм идарәне гамәлгә куючылары тарафыннан инвестицияләүне күздә тоткан мөлкәт белән ышанычлы идарә итүне туктатырга.» сүзләрен өстәргә;

- Нигезләмәнең 2.8 пунктының 4 пунктчасына «чит дәүләтләрнең банкларына һәм башка оешмаларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

Нигезләмәнең 2 өлешен түбәндәге эчтәлекле 2.8.1 пункты белән тулыландырырга:

«2.8.1 «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 13.4 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә тикшерүләр үткәрүгә бәйле сораулардан тыш, чит ил банклары һәм башка чит ил оешмаларына, шулай ук чит дәүләтләрнең вәкаләтле органнарына сораулар Россия Федерациясе

Прокуратурасы органнары нигезендә һәм Россия Федерациясе Генераль прокуроры тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә җибәрелә.»

Нигезләмәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 1.9 пункт өстәргә:

«1.9. Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларындагы счетларның (кертемнәрнең), кулдагы акчаларның һәм кыйммәтләрнең Нигезләмәнең, 1.2 пунктында күрсәтелгән затлар тарафыннан Россия Федерациясе законнарына яисә чит дәүләт законнарына туры һәм читләтелгән (өченче затлар аша) чит ил финанс инструментларын биләүгә һәм (яисә) алардан файдалануга карата мирас кабул иткән, шулай ук чит дәүләт законнары нигезендә гамәлгә куелган нәселдәнлек мөлкәте (мирас фонды, траст) белән ышанычлы идарә итүне гамәлгә куючы һәм (яисә) бенефициар статусын алга очракта, күрсәтелгән затлар мирас алган яисә чит ил финанс инструментларын гамәлгә куючыга һәм (яисә) нәселдәнлек мөлкәте белән ышанычлы идарә итү бенефициарына тапшырган көннән алып алты ай эчендә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетларны (кертемнәрне) ябарга, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны туктатырга, һәм (яисә) алынган чит ил финанс инструментларыннан читләштерүне гамәлгә ашырырга, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) файдалануны башка ысул белән туктатырга.»

- Нигезләмәнең 2.12 пунктында «1-6 пунктчалар» сүзләрен «1-7 пунктчалар»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы: А. Ф. Никошин